**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районы**
**Урсай авыл җирлеге Советы**

# КАРАР

**30.05.2022 ел** **№ 50**

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Урсай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар башкаручылар һәм контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүматларны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгару өчен бирү тәртибен раслау турында» 2017 елның 25 сентябрендәге 77 номерлы Зәй муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 01 апрелендәге 90-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Зәй муниципаль районының Урсай авыл җирлеге Уставына таянып, Зәй муниципаль районының Урсай авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1.Зәй муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Советының 2017 елның 25 сентябрендәге 77 номерлы карары белән расланган (2021 елның 15 июлендәге 32 номерлы карар нигезендә кертелгән үзгәреш белән)«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Урсай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар башкаручылар һәм контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүматларны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгару өчен бирү тәртибенең 3 пункты«г» пунктчасына,аннан « акцияләр» сүзен төшереп калдырып, үзгәреш кертергә.

2. Карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU), җирлек торак пунктлары территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Совет рәисе** **Н.А.Гатина**